РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

08.12.2016 №1503-п

Татарстан Республикасы Саба муниципаль
районы Башкарма комитетының 31.03.2006 N 109-п
карары белән расланган Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районының Административ комиссиясе
эш регламентына үзгәрешләр кертү турында

"Башкару эшчәнлеге турында" Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" 05.04.2013 N 49-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясы, "Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына административ комиссияләр төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында" 2005 елның 30 декабрендәге 144-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Саба муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Административ комиссия төзү һәм аның эшчәнлеген оештыру турында» Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 31.03.2006 N 109-п карары белән расланган Саба муниципаль районы Административ комиссиясенең эш регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Административ комиссия үз вәкаләтләрен Россия Федерациясе Конституциясе һәм Татарстан Республикасы Конституциясе, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары карарлары, Саба муниципаль районы Уставы, Саба муниципаль районы Башкарма комитетының муниципаль хокукый актлары, башка норматив-хокукый актлар, шулай ук әлеге Регламент нигезендә гамәлгә ашыра.»;

2) 2.12 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.12 Саба муниципаль районының Административ комиссиясендә килүчеләрне кабул итәләр. Административ комиссия адресына гражданнардан һәм юридик затлардан кергән шикаятьләр һәм мөрәҗәгатьләр гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда карала.»;

3) 2.4 пунктына түбәндәге эчтәлекле икенче абзац өстәргә:

"Җаваплы сәркатип булмаган очракта, аның вазыйфаларын административ комиссия рәисе билгеләгән административ комиссия әгъзаларының берсе башкара.";

4) 5.3 пунктта «утыз» сүзен «алтмыш» сүзенә алмаштырырга;

5) 5.6 пунктта «утыз» сүзен «алтмыш» сүзенә алмаштырырга;

6) 2.14 пунктта «ай саен» сүзен «квартал саен» сүзенә алмаштырырга;

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Саба муниципаль районының регламент, хокук тәртибе һәм халыкның иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районының
Башкарма комитеты
Җитәкчесе Р.М.Гасимов